**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегенең Әхмәт авылы торак пунктында гражданнар җыены**
**КАРАРЫ**

**18 октябрь 2022 ел** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Әхмәт авыл җирлегенең Әхмәт авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ**:**

1. 2023 елда Нурлат муниципаль районының Әхмәт авыл җирлеге Әхмәт авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1нче төркем инвалидлардан, балачактан инвалид булганнардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, сугышчан хәрәкәтләр ветераннары, 75 яшьтән өлкәнрәк ялгыз яшәүче гражданнардан кала, һәр балигъ булган кешедән 2000 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы тоту;
- су белән тәэмин итү чыганакларына карата норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр.

Халык җыенында рәислек итүче: Г.Н. Лизратова

Әхмәт авыл җирлеге башлыгы: Г.Н. Лизратова